# БЕРДӘМ ТАВЫШ БИРҮ КӨНЕ: нинди яңалыклар һәм үзенчәлекләр бар?

## Башкортстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Илона Макаренко белән әңгәмә



**– Быел Бердәм тавыш бирү көне 13 сентябрьгә туры килә. Бу көнне безнең республика территориясендә нинди дәрәҗә сайлаулар узачак?**

– Агымдагы елда республикада күпсанлы муниципаль сайлау кампанияләре үтәчәк. Аерым алганда, Уфа һәм Межгорье шәһәрләреннән тыш, барлык шәһәр округларында, муниципаль район, шәһәр һәм авыл биләмәләрендә урындагы үзидарә органнарына депутатлар сайлау үтәчәк. Урындагы сайлауларда 1760 мандат алмаштырылачак, аларның яртысыннан күбесе (903 мандат) муниципаль район Советларына депутатлар сайлауга туры килә. Моннан тыш, Уфаның Совет районында яшәүчеләр – Дәүләт Җыелышы-Корылтайга 14нче Новиковка округы буенча, ә Белорет районы һәм Межгорье шәһәре гражданнары 5нче Металлургия округы буенча өстәмә сайлауларда катнашачак. Тоташ алганда, республика буенча 206 сайлау кампаниясе узачак.

**– Билгеле булуынча, барлык дәрәҗәдә дә депутатлыкка кандидатларны тәкъдим итү һәм аларны теркәү этабы тәгәлләнде. Аның нәтиҗәләре нинди?**

– Барлык дәрәҗә сайлауларда үз кандидатураларын 4 799 кеше тәкъдим итте, 27 августка булган мәгълүматларга караганда, шулардан 4 416 кандидат теркәлгән. Теркәлгән кандидатларның якынча 20 проценты сайлауларда үз-үзен күрсәтү тәртибендә катнаша, калганнарын 10 сәяси партия тәкъдим итә: "Бердәм Русия" – 1777 кандидат, КПРФ – 456, "Русия патриотлары" – 422, ЛДПР – 390, Гадел Русия – 258, "Яшелләр" Русия экология партиясе – 81, "Үсеш партиясе" – 40, "Социаль гаделлек өчен Русия пенсионерлар партиясе" – 32, "Гражданнар Платформасы" – 31, "Яблоко" – 24.

**– Сайлаулар 13 сентябрьдә узачак. Бу сайлаучылар тавыш бирә алган бердәнбер көнме?**

– Законнар тавыш бирү өчен берничә төр мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Башкортстанның Сайлаулар турында кодексында тавыш бирү бинасында урындагы үзидарәнең вәкиллекле органнарына сайлауларда вакытыннан алда тавыш бирү турында норма каралган.

– Башкортстанның Сайлаулар турында кодексында каралган вакытыннан алда тавыш бирү сайлаучы гаризасы буенча участок сайлау комиссиясе тарафыннан тавыш бирү бинасында уздырыла. Анда ул вакытыннан алда тавыш бирергә карар иткән сәбәпләрне күрсәтергә тиеш – отпуск, командировка, уку, сәламәтлек торышы һәм башка җитди сәбәпләр. Бу төр тавыш бирүдә тутырылган бюллетень үтәкүренмәле булмаган конвертка салына, ул комиссия секретаренда тавыш бирү көненә кадәр саклана. Сайлаулар турындагы кодекска ярашлы, вакытыннан алда тавыш бирү эш көннәрендә кичке якта һәм ял көннәрендә дүрт сәгатьтән дә ким булмаган вакыт аралыгында үткәрелә. Ул тавыш бирүгә 10 көн кала башланырга тиеш. Быел – 2 сентябрьдән.

Русия Үзәк сайлау комиссиясенең агымдагы елның 24 июлендәге карары нигезендә, алдан тавыш бирү сайлау комиссиясе бинасында да, аннан читтә дә башкарылырга мөмкин, ягъни тавыш бирүнең төрле төрләре рөхсәт ителә. Шул ук вакытта, өйдә тавыш бирү очракларыннан тыш, сайлаучыдан алдан тавыш бирү турында гариза таләп ителми. Тавыш бирү төренә карап, тавыш бирү өчен стационар яки күчмә тартмалар кулланыла, ә тутырылган бюллетеньнәр сейф-пакетларда саклана. Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә, Сайлаулар турындагы кодекста каралган вариантттан аермалы буларак, алдан тавыш бирү Бердәм тавыш бирү көненә ике көн кала уздырыла. Быел алдан тавыш бирү 11 һәм 12 сентябрьдә узачак.

Башка принципиаль моментлар да бар. Әйтик, территориаль сайлау комиссиясе Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе карарында күз уңында тотылган тавыш бирүне оештыруның өстәмә төрләрен куллану турында карар кабул итсә, ә урындагы сайлауларда аның мондый хокукы бар, алдан тавыш бирү, Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе карары таләпләренә ярашлы, 2020 елның 13 сентябреннән алдагы ике көндә (алда әйтелгәнчә, 11 һәм 12 сентябрь), ә аңа кадәр тугыз көн дәвамында (2-10 сентябрьдә) Сайлаулар турында кодекс нормалары буенча оештырылачак.

Әмма пандемия безнең көндәлек тормышыбызга гына түгел, сайлауларда тавыш бирү процессына да төзәтмәләр кертте. Шуңа күрә Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе, федераль законнарга ярашлы, тавыш бирүнең өстәмә төрләрен тәкъдим итте: тавыш бирү өчен бинадан тыш (өйдә), йорт яны территорияләрендә вакытыннан алда тавыш бирү һәм тавыш бирү урыннары булмаган һәм еракта урнашкан торак пунктларда сайлаучылар төркемнәренең вакытыннан алда тавыш бирүе.

**– Вакытыннан алда тавыш бирүнең бу төрләре арасында нинди аерма бар?**

**– Сайлауларда өстәмә тавыш бирүнең теге яки бу төрләрен файдалану буенча сайлау комиссияләренең карарлары бармы?**

– Сайлауларны оештыручы 63 территориаль сайлау комиссиясенең 30га якыны шундый карар кабул итте. Республика Үзәк сайлау комиссиясе Дәүләт Җыелышы-Корылтай депутатларын өстәмә сайлауларда 11 һәм 12 сентябрьдә вакытыннан алда тавыш бирү төрләрен (тавыш бирү бинасында һәм тавыш бирү бинасыннан тыш) куллану турында карар кабул итте.

**– Кайбер экспертлар тавыш бирүнең берничә төрен куллану (бигрәк тә алдан тавыш бирү) сайлаулар барышына җәмәгать контролен катлауландыра дигән фикердә...**

– Безнең комиссияләр, сайлау процессының үтәкүренмәлелеген тәэмин итеп, ачыклык һәм хәбәрдарлык режимында эшли. Тавыш бирүнең һәрбер көнендә, шул исәптән вакытыннан алда тавыш бирүдә, кандидатлардан, сайлау берләшмәләреннән, Иҗтимагый палатадан күзәтүчеләр сайлаулар барышын контрольдә тота ала. Русиянең һәм Башкортстанның Үзәк сайлау комиссияләрендә аккредитация үткән журналистлар да тавыш бирү процессын күзәтә, киңкүләм мәгълүмат чараларында сайлаулар барышын һәм нәтиҗәләрен объектив яктырта ала.

**– Узган сайлауларда сайлаучылар "мобиль сайлаучы" системасыннан киң файдаланды. Быел ул эшләячәкме?**

– Быел Башкортстан территориясендә "Мобиль сайлаучы" системасын бары тик Дәүләт Җыелышы-Корылтай депутатларын өстәмә сайлауларда гына, ягъни бер мандатлы Новиковка һәм Металлургия сайлау округларында гына файдаланырга мөмкин.

Тавыш бирү көнендә яшәү урыныннан тыш, әмма "үз" сайлау округы чикләрендә булачак сайлаучы үзен урнашу урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертү турында гариза тапшырырга хокуклы. Гаризалар 29 июльдә үк кабул ителә башлады һәм бу 8 сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Урнашу урыны буенча тавыш бирү турында гаризалар кабул итүче территориаль комиссияләрнең, шулай ук күпфункцияле җәйләнмаларның адреслары республика Үзәк сайлау комиссиясе сайтында һәм аның социаль челтәрләрдәге битләрендә урнаштырылган. Гаризаны "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша да бирергә мөмкин. 2 сентябрьдән 8 сентябрьгә кадәр атап үтелгән сайлау округларының участок сайлау комиссиясенә гариза белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин.

**– Башкортстанда читтән торып электрон тавыш бирү көтеләме һәм республикада үтәчәк сайлауларның кайсысында Мәскәүдә санлы участокларда тавыш бирергә мөмкин?**

– Республика территориясендә читтән торып электрон тавыш бирү булмаячак. Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә, агымдагы елда ике субъект – Курск һәм Ярославль өлкәләре территориясендә генә Дәүләт думасы депутатларын өстәмә сайлауларда электрон тавыш бирү үткәрелә.

Мәскәүдә санлы участокларда тавыш бирүгә килгәндә, бу мөмкинлектән бары тик бермандатлы Новиковка һәм Металлургия округлары сайлаучылары гына файдалана ала.

Моның өчен бермандатлы сайлау округлары чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлергә, шулай ук, санлы сайлау участогында сайлаучылар исемлегенә кертү турында гариза тапшырырга кирәк. Гариза бирү тәртибе белән Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе сайтында танышырга мөмкин.

**– Коронавирус пандемиясенә бәйле хәл-шартларда тавыш биргәндә нинди хәвефсезлек чаралары күреләчәк?**

– Мәгълүм булуынча, ил Конституциясенә төзәтүләр буенча гомумрусия тавыш бирү чарасын әзерләгәндә һәм үткәргәндә сайлау комиссияләре "Роспотребнадзор"ның Русиянең Үзәк сайлау комиссиясе белән килешенгән тәкъдимнәренә таянып эш иткән иде. Алар үз көченә кала һәм Бердәм тавыш бирү көненә әзерлек һәм аны үткәрү вакытында сайлау комиссияләре тарафыннан кулланылачак. Алар – тавыш бирүдә катнашучыларга тән температурасы контроле, кулларны дезинфекцияләү, санитар дистанцияне саклау өчен махсус линия-күрсәткечләр, өслекләрне дезинфекцияләү, бер тапкыр кулланыла торган перчаткалар, комиссия әгъзалары өчен экраннар һәм башкалар. Сайлау комиссияләре шәхси саклану чаралары, шул исәптән махсус, антисептик һәм дезинфекция чаралары белән тиешле күләмдә тәэмин ителә. Урындагы үзидарә органнары белән тыгыз хезмәттәшлектә бу юнәлештә эш алып барыла.

**– 13 сентябрьдә тавыш бирүгә бәйле сораулар туса, сайлаучылар кайда мөрәҗәгать итә ала?**

– Башкортстанның Үзәк сайлау комиссиясендә агымдагы елның 29 июленнән сайлаучылар белән элемтә өчен "кайнар линия" эшли. Республика халкы сорауларына Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзалары һәм Комиссия аппараты хезмәткәрләре җавап бирә. "Кайнар линия" телефоннары – **8 (347) 280-95-06, 8 (347) 280-96-34.** Русия Үзәк сайлау комиссиясе мәгълүмат-белешмә үзәгенең **8-800-200-00-20** номеры буенча шалтыратырга да мөмкин.

Исегезгә төшерәм, алда торган сайлау кампанияләре турында барлык мәгълүмат Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе сайтында "Сайлаулар 2020" бүлегендә, шулай ук, комиссиянең "Facebook", "ВКонтакте" һәм "Одноклассники" социаль челтәрләрендәге битләрендә урнаштырылган.

**Ринат ГАФУРОВ әңгәмәләште.**